| | |
|---|---|
| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО БИОЛОГИЧЕСКИМ РЕСУРСАМ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ БИОЛОГИК РЕСУРСЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |

**Приказ** 11.11.2020 **г. Казань** **Боерык** 346-од

Региональ әһәмияттәге аерым саклана торган табигый территория чикләрендә индивидуаль торак төзелеше объектларын, бакча йортларын төзүне, үзгәртеп коруны гамәлгә ашырганда (дәвалау-савыктыру урыннары һәм курортлардан тыш), җир кишәрлегендә төзелгән яки үзгәртеп корылган индивидуаль торак төзелеше объектларының яки бакча йортының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон таләпләренә туры килүе (туры килмәве) турында хәбәрнамәләр бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, 1995 елның 14 мартындагы 33-ФЗ номерлы «Аеруча саклаулы табигать территорияләре турында», 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында», 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»гы федераль законнар нигезендә, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә боерам:

1. Кушылып бирелгән Региональ әһәмияттәге аерым саклана торган табигый территория чикләрендә индивидуаль торак төзелеше объектларын, бакча йортларын төзүне, үзгәртеп коруны гамәлгә ашырганда (дәвалау-савыктыру урыннары һәм курортлардан тыш), җир кишәрлегендә төзелгән яки үзгәртеп корылган индивидуаль торак төзелеше объектларының яки бакча йортының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон таләпләренә туры килүе (туры килмәве) турында хәбәрнамәләр бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламентын расларга.

2. Рәис урынбасарларына, структур бүлекчәләр җитәкчеләренә, дәүләт хезмәте күрсәтүне турыдан-туры тәэмин итүче затларга Регламент нигезләмәләрен үтәүне һәм алар тарафыннан каралган документларны алып баруны тәэмин итәргә.

3. Хокукый эш буенча әйдәп баручы киңәшчегә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 10.09.2010 ел, 729 нчы номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасы турындагы нигезләмәгә туры китереп, әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алуны һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестрына кертү өчен Регламентны җибәрүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны рәис урынбасары Р. Г. Шәрәфетдиновка йөкләргә.

Рәис Ф.С. Батков

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2020 елның 11 нче ноябреннән 346-од номерлы боерыгы белән расланган

Региональ әһәмияттәге аерым саклана торган табигый территория чикләрендә индивидуаль торак төзелеше объектларын, бакча йортларын төзүне, үзгәртеп коруны гамәлгә ашырганда (дәвалау-савыктыру урыннары һәм курортлардан тыш), җир кишәрлегендә төзелгән яки үзгәртеп корылган индивидуаль торак төзелеше объектларының яки бакча йортының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон таләпләренә туры килүе (туры килмәве) турында хәбәрнамәләр бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламенты

## 1. Гомуми кагыйдәләр

1.1. Аерым саклана торган региональ әһәмияттәге табигый территория чикләрендә индивидуаль торак төзелеше объектларын, бакча йортларын төзүне, үзгәртеп коруны гамәлгә ашырганда (дәвалау-савыктыру урыннары һәм курортлардан тыш), җир кишәрлегендә төзелгән яки үзгәртеп корылган индивидуаль торак төзелеше объектларының яки бакча йортының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон таләпләренә туры килүе (туры килмәве) турында хәбәрнамәләр бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламенты (алга таба – Регламент, дәүләт хезмәте), дәүләт хезмәтен күрсәтүнең стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр - физик һәм юридик затлар (алга таба – мөрәҗәгать итүчеләр).

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты тарафыннан күрсәтелә ( алга таба – Комитет).

1.3.1. Комитетның урнашу урыны: Казан, Кәрим Тинчурин урамы, 29 йорт.

Комитетның эш вакыты: шимбә һәм якшәмбедән кала, көн саен, дүшәмбе – пәнҗешәмбе 9.00-18.00, җомга 9.00-16.45. Төшке аш 13.00-13.45.

Гаризаларны кабул итү графигы: шимбә һәм якшәмбедән кала, көн саен, дүшәмбе – пәнҗешәмбе 9.00-18.00, җомга 9.00-16.45. Төшке аш 13.00-13.45.

Иҗтимагый транспорт белән “Татарстан” тукталышына кадәр :

автобуслар № 1, 31, 53, 54, 6, 71;

троллейбуслар №3, 5;

“Ахтямов” тукталышына кадәр :

автобуслар № 23,5, 56, 68, 71, 72.

Керү шәхесне раслый торган документ буенча.

1.3.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе һәм аның барышы турында мәгълүмат бирү Биотөрлелек бүлеге (алга таба – Бүлек) белән башкарыла. Телефон: (843) 211-70-78.

1.3.3. Комитетның мәгълүмати-телекомммуникатив “Интернет” челтәрендә, “Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Реестры”дәүләт мәгълүмати системасына керә торган, рәсми сайт адресы http://www.ojm.tatar.ru, электрон почта адресы: ojm@tatar.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат алынырга мөмкин:

1) мәгълүмати-телекоммуникатив “Интернет” челтәре аша:

-Комитетның рәсми сайтындаhttp://www.ojm.tatar.ru;

-Татарстан Республикасының Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatar.ru/);

-Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләренең бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru);

- Татарстан Республикасының Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatar.ru/) һәм Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://www.gosuslugi.ru).

3) Комитетка телдән мөрәҗәгать итеп

- шәхси (102 кабинет);

-телефон аша (843)211-70-78.

4) Комитетка язмача мөрәҗәгать итеп (шул санда ojm@tatar.ru рәсми электрон почтага җибәрелгән электрон документ рәвешендә).

5) Комитетның биналарында дәүләт хезмәте турында турыдан-туры күреп һәм текстлы мәгълүмат булган, дәүләт хезмәте турында мәгълүмати стендлар ярдәмендә.

1.3.5. Комитетның урнашу урыны, белешмә өчен телефоннары, эш графигы, рәсми сайт адресы, электрон почтасы, Бүлек белгече тарафыннан Комитетның рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында урнаштырыла.

Комитетның мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү биналарындагы мәгълүмати стендларда урнаштырылган мәгълүмат, Татарстан Республикасының дәүләт телләрендә урнаштырыла һәм үз эченә дәүләт хезмәте турында әлеге Регламентның 1.3.1, 2.1, 2.3 - 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 нче пунктларда күрсәтелгән мәгълүматны ала.

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Комитетның рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры»дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган.

1.5. Бу регламентта киләсе атамалар һәм билгеләмәләр кулланыла:

региональ әһәмияттәге аерым саклана торган табигый территория – Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының карарлары белән, тулысынча яки өлешчә хуҗалык файдалануыннан алынган һәм алар өчен билгеләнгән махсус саклау режимы урнаштырылган, аеруча табигать саклау, фәнни, мәдәни, эстетик, ял итү һәм сәламәтлекне саклау әһәмиятенә ия булган, табигать комплекслары һәм объектлары урнашкан җир бүлемтеге, су өсте һәм аларның өстендәге һава киңлеге.

индивидуаль торак төзелеше объекты-гражданнар тарафыннан мондый бинада яшәүгә бәйле көнкүреш һәм башка ихтыяҗларны канәгатьләндерү өчен билгеләнгән бүлмәләрдән һәм ярдәмче куллану бүлмәләреннән торган һәм мөстәкыйль күчемсез милек объектларына бүлү өчен билгеләнмәгән, җир өсте катлары 3 тән дә, биеклеге егерме метрдан да артмаган аерым торучы бина.

бакча йорты-гражданнар тарафыннан көнкүреш һәм башка ихтыяҗларны канәгатьләндерү өчен билгеләнгән, аларның вакытлыча төзелүенә бәйле булган биналар, корылмалар, шул исәптән җимерелә торган капиталь төзелеш объектлары урынында төзелә торган сезонлы куллану биналары;

линия объектларны үзгәртеп кору – сыйныфын, дәрәҗәсен һәм (яки) мондый объектларның башта билгеләнгән функцияләрен(егәрлек, йөк күтәрү һәм башкалар) үзгәртүгә китерүче яки мондый объектларның чыгару сызыклары чикләрен һәм (яки) саклау зоналарын үзгәртүне таләп итүче,линия объектларының яки аларның кишәрлекләренең (өлешләренең)параметрларын үзгәртү;

капиталь төзелеш объектларын үзгәртеп кору (линия объектларыннан кала) – капиталь төзелеш объектының, аның өлешләренең (биеклек, күп катлылык, мәйданы, күләме), шул исәптән капиталь төзелеш объектын кушып төзү, үзгәртеп кору, киңәйтү ә шулай ук, шундый конструкцияләрнең аерым элементларын шундый ук яки мондый конструкцияләрнең күрсәткечләрен яхшыртучы башка элементларга алыштырудан һәм (яки) күрсәтелгән элементларны яңадан торгызудан кала, капиталь төзелеш объектының тотып торучы төзелеш конструкцияләрен алыштыру һәм (яки) торгызу параметрларын үзгәртү;

инженерлык тикшеренүләре - территорияләрне һәм аның чикләрендәге җирләрне рациональ һәм һәвефсез файдалану максаты белән, техноген йогынтысының табигый шартларын һәм факторларын өйрәнү, территориаль планлаштыру һәм архитектура-төзелеш проектлары өчен кирәкле материалларны нигезләү буенча мәгълүматларны әзерләү;

кызыл линияләр – гомуми файдаланудагы территорияләр чикләрен билгели торган һәм территорияне планлаштыру документларында билгеләнергә, үзгәртелергә яки гамәлдән чыгарылырга тиешле линияләр;

төзүче – үзенең җир кишәрлегендә яисә башка хокук иясенең җир кишәрлегендә (дәүләт (муниципаль) милектәге капиталь төзелеш объектларына бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашырганда, дәүләт хакимияте органнары (дәүләт органнары), Атом энергиясе буенча «Росатом» дәүләт корпорациясе, Галәм эшчәнлеге буенча «Роскосмос» дәүләт корпорациясе, дәүләти бюджетныкы булмаган фондларның идарә органнары яки җирле үзидарә органнары Россия Федерациясенең бюджет законнарында билгеләнгән очракларда, килешүләр нигезендә үзләренең дәүләт (муниципаль) заказчысы вәкаләтләрен яки « Төзүчеләрнең бөлгенлеккә төшү очрагында өлешләп төзүдә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау буенча ачык - хокукый компания турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль законның 13.3 статьясы нигезендә, килешүләр нигезендә, үзләренең төзүче функцияләрен тапшырган) капиталь төзелеш объектларын төзүне, үзгәртеп коруны, аларга капиталь ремонт ясауны, сүтүне, шулай ук инженерлык эзләнүләрен башкаруны, аларны төзү, үзгәртеп кору, капиталь ремонтлау өчен проект документларын әзерләүне тәэмин итүче физик яки юридик зат. Төзүче шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнарда каралган үз функцияләрен, техник заказчыга тапшырырга хокуклы;

техник хата - дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган тарафыннан ясалган һәм документка кертелгән мәгълүматларның(дәүләт хезмәте нәтиҗәсе), алар нигезендә мәгълүматлар кертелгән документларга тәңгәл килмәвенә китергән хата(хәреф хатасы, грамматик яки арифметик хата);

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкнең читтән торып эш урыны- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 22

декабреннән «Күп функцияле үзәкләр тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү эшчәнлегенең кагыйдәләрен раслау турында»гы 1376 нчы карары белән расланган , Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы муниципаль районының шәһәр округы яки яки шәһәрдә (авыл җирлегендә) төзелгән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкнең территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офис).

Әлеге Регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гариза астында дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мөрәҗәгать аңлашыла («Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба - 210-ФЗ номерлы Федераль закон) 2 ст.1 п.). Гаризаларның тәкъдим ителә торган формасы әлеге Регламентның 1 нче кушымтасында китерелгән.

## 2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандартына куела торган таләпнең исеме | Стандартка куела торган таләпнең эчтәлеге | Таләпне яки дәүләт хезмәтен билгеле торган норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1.Дәүләт хезмәтенең атамасы | Региональ әһәмияттәге аерым саклана торган табигый территория чикләрендә индивидуаль торак төзелеше объектларын, бакча йортларын төзүне, үзгәртеп коруны гамәлгә ашырганда (дәвалау-савыктыру урыннары һәм курортлардан тыш), җир кишәрлегендә төзелгән яки үзгәртеп корылган индивидуаль торак төзелеше объектларының яки бакча йортының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон таләпләренә туры килүе (туры килмәве) турында хәбәрнамәләр бирү | Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 55 ст. (алга таба-ШтК); Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре»15.12.2017 ел, 996 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмәнең 4.3.11 п. (алга таба – Татарстан |

| | | |
|---|---|---|
| | | Республикасы Министрлар Кабинетының 996 нчы карары белән расланган нигезләмә). |
| 2.2. Башкарма хакимият органының исеме | Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты | 996 нчы номерлы карар белән расланган нигезләмә |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенең тасвирламасы | 1) Региональ әһәмияттәге аерым саклана торган табигый территория чикләрендә индивидуаль торак төзелеше объектларын, бакча йортларын төзүне, үзгәртеп коруны гамәлгә ашырганда (дәвалау-савыктыру урыннары һәм курортлардан тыш), җир кишәрлегендә төзелгән яки үзгәртеп корылган индивидуаль торак төзелеше объектларының яки бакча йортының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон таләпләренә туры килүе турында хәбәрнамә (алга таба – туры килү турында хәбәрнамә);<br>2) Региональ әһәмияттәге аерым саклана торган табигый территория чикләрендә индивидуаль торак төзелеше объектларын, бакча йортларын төзүне, үзгәртеп коруны гамәлгә ашырганда (дәвалау-савыктыру урыннары һәм курортлардан тыш), җир кишәрлегендә төзелгән яки үзгәртеп корылган индивидуаль торак төзелеше объектларының яки бакча йортының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон таләпләренә туры килмәве турында хәбәрнамә (2 нче һәм 3 нче кушымта) (алга таба-туры килмәү турында хәбәрнамә);<br>3) Хәбәрнамәне карамыйча кире кайтару. | РФ ШтК 55 ст, 17,19,20 пп. |

| | | |
|---|---|---|
| 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, әгәр Россия Федерациясе законнарында каралса, Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору вакыты, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документларны бирү (җибәрү) вакыты. | Туры килү (туры килмәү) турында хәбәрнамәне бирү процедурасын гамәлгә ашыру вакыты индивидуаль торак төзелеше яки бакча йорты объектын төзү яки үзгәртеп кору тәмамлану турында хәбәр килгән көннән җиде эш көне тәшкил итә (алга таба - төзелеш тәмамлану турында хәбәрнамә).<br>Хәбәрнамәне карамыйча кире кайтару, төзелешнең тәмамлануы турында хәбәрнамә кергән көннән өч эш көне эчендә.<br>Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документ гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып (почта аша яки электрон адреска) дәүләт хезмәте нәтиҗәсен рәсмиләштерү һәм теркәү көнендә гамәлгә ашырыла.<br>Законда дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору каралмаган. | РФ ШтК 55 ст, 17,19 пп. |
| 2.5. Дәүләт хезмәте, шулай ук мөрәҗәгать итүчегә күрсәтелергә тиешле дәүләт хезмәтләрен күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен закон яки башка норматив-хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге, гариза бирүче белән аларны алу ысуллары, шул санда электрон рәвештә, | Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Индивидуаль торак төзелеше яки бакча йорты объектын төзү һәм үзгәртеп кору өчен кирәкле хәбәрнамәләр формаларын раслау турында» 2018 елның 19 сентябрендәге 591/пр номерлы боерыгы (алга таба – Россия Төзелеш Министрлыгының №591/пр боерыгы) белән расланган формада төзелешне тәмамлау турында хәбәрнамә (әлеге Регламентка 1 нче кушымта).<br>Төзелешнең тәмамлануы турындагы хәбәрнамәгә түбәндәге документлар теркәлә:<br>1) хәбәрнамә төзүче вәкиле тарафыннан җибәрелгән очракта, төзүче вәкиленең вәкаләтен раслый торган документ;<br>2) төзүче чит ил юридик заты булган очракта, чит ил дәүләте законнары нигезендә юридик затны дәүләт теркәвенә алу | РФ ШтК 55 ст., «Төзелешкә рөхсәт бирү һәм файдалануга тапшыру өчен рөхсәт бирү өчен кирәкле документларны электрон формада җибәрү турында» 2017 елның 27 сентябрендәге 729 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары |

| | | |
|---|---|---|
| аларны күрсәтү тәртибе. | турындагы рус теленә тәрҗемә ителгән һәм расланган документлар;<br>3) индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йортының техник планы;<br>4) җир кишәрлегенә ия булучылар арасында, шәхси торак төзелеше объекты яки бакча йорты төзелгән яки үзгәртеп корылган җир кишәрлеге гомуми өлешле милек хокукында яки арендатор ягында күп санлы затлар белән аренда хокукында ике һәм аннан да күбрәк гражданныкы булган очракта, төзелгән яки үзгәртеп корылган индивидуаль торак төзелеше объектларына яки бакча йортына гомуми өлешле милек хокукында аларның өлешен билгеләү турында килешү.<br>Дәүләт хезмәтен алыр өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче шәхси Комитеттан алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы Комитетның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм аңа кушылган документлар, мөрәҗәгать итүче белән, кәгазьдә киләсе ысуллар белән тапшырыла ала:<br>шәхси (ышанычнамә нигезендә гариза бирүче исеменнән эш итүче зат белән);<br>почта аша.<br>Документлар, гариза бирүче белән, электрон имза белән расланып, шулай ук электрон рәвештә, “Интернет” челтәре мәгълүмат ресурслары яки Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша юнәлтелергә мөмкин.<br>Мөрәҗәгать итүче, «Электрон култамга турында» 06.04.2011 ел, 63-ФЗ номерлы, 210-ФЗ номерлы федераль законнар таләпләре нигезендә, техник мөмкинлек булган очракта, «Татарстан Республикасының Электрон Хөкүмәте» дәүләт | |

| | | |
|---|---|---|
| | мәгълүмат системасы аша, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре аша, шул исәптән «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә гариза һәм документларны тапшырырга (җибәрергә) хокуклы. | |
| 2.6. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагындагы, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен норматив-хокукый актлар нигезендә, гариза бирүче тапшырырга хокуклы булган кирәкле документларның тулы исемлеге, ә шулай ук мөрәҗәгать итүче белән аларны алу ысуллары, шул санда электрон рәвештә;аларны бирү тәртибе. | Әлеге категориягә караган документларны тапшыру таләп ителми. | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Документлар кабул итүдән баш тарту өчен нигез юк | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту | Дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр: | РФ ШтК 55 ст., 17,20 п.п. |

| | | |
|---|---|---|
| өчен нигезләрнең тулы исемлеге | 1. туры килмәү турындагы хәбәрнамә җибәрү өчен нигезләр:<br>а) индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йортының төзелгән яисә үзгәртеп корылган объектларының параметрлары РФ ШтК 55 статьясындагы 19 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән, җирдән файдалану һәм төзелеш объектлары, территорияне планлаштыру буенча документларда билгеләнгән капиталь төзелеш объектларының РФ ШтК, башка федераль законнарда билгеләнгән мәҗбүри таләпләренә туры килмәве;<br>б) индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йортының тышкы кыяфәте планлаштырыла торган төзелеш турында хәбәрнамәгә кушымта булган мондый объектның яки йортның тышкы кыяфәте тасвирламасына яки планлаштырыла торган төзелеш турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән типлаштырылган архитектура карарына туры килмәү, яки төзүчегә индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йорты параметрларының планлаштырыла торган параметрлары турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән параметрларга туры килмәве һәм (яки) федераль яки региональ әһәмияттәге тарихи җирлек чикләрендә индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын төзү яки үзгәртеп кору очрагында, ШтК $51^1$ статьясындагы 10 өлешенең 4 пунктында күрсәтелгән нигез буенча, җир кишәрлегендә индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йорты объектын яки бакча йортын урнаштыруга юл куелмау турында хәбәрнамә җибәрелү.<br>в) төзелгән яки үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының рөхсәт ителгән файдалану төре, планлаштырыла торган төзелеш турындагы хәбәрнамәдә күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше объектыннан яки бакча йортыннан рөхсәт ителгән файдалану төренә туры килми; | |

| | | |
|---|---|---|
| | г) капиталь төзелеш объектын төзүгә, үзгәртеп коруга карата кабул ителгән, территориядән файдалануның махсус шартлары булган зонаны билгеләү яки үзгәртү турында карарда күрсәтелгән чикләүләр каралган һәм мондый капиталь төзелеш объекты эксплуатациягә кертелмәгән очраклардан тыш, индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын урнаштыру Россия Федерациясенең Җир һәм башка законнары нигезендә төзелеш тәмамлану турында хәбәрнамә кергән көнгә билгеләнгән чикләүләргә туры килми.<br>2. хәбәрнамәне карамыйча кире кайтару өчен нигезләр:<br>а) төзелешнең тәмамлануы турында хәбәрнамәдә түбәндәге белешмәләрнең булмавы:<br>төзүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәү урыны, шәхесне раслаучы документ реквизитлары (физик зат өчен));<br>мөрәҗәгать итүче чит ил юридик заты булган очрактан тыш, төзүче (юридик зат өчен) атамасы һәм урнашу урыны, шулай ук юридик затның бердәм дәүләт регистрациясе турындагы язмасының дәүләт теркәү номеры һәм салым түләүченең идентификация номеры;<br>җир кишәрлегенең кадастр номеры (булганда), җир кишәрлегенең адресы яки тасвирламасы;<br>төзүченең җир кишәрлегенә хокукы турында белешмәләр, шулай ук җир кишәрлегенә башка затларның хокуклары турында белешмәләр (андый затлар булганда));<br>җир кишәрлегеннән һәм капиталь төзелеш объектыннан (индивидуаль торак төзелеше яки бакча йорты объектыннан) рөхсәт ителгән файдалану рәвеше турында белешмәләр; | |

| | | |
|---|---|---|
| | индивидуаль торак төзелеше объекты яки бакча йорты, мөстәкыйль күчемсез милек объектларына бүленмәячәге турында мәгълүмат;<br>төзүче белән элемтә өчен почта адресы һәм (яки) электрон почта адресы;<br>индивидуаль торак төзү объектиның яки бакча йортының төзелгән яки үзгәртеп корылган параметрлары турында белешмә;<br>хокукларны дәүләт теркәвенә алу өчен дәүләт пошлинасын түләү;<br>төзүчегә хәбәр җибәрү ысулы турында белешмә.<br>б) төзелеш тәмамлану турындагы хәбәрнамәгә әлеге Регламентның 2.5 пунктында каралган документлар беркетелмәгән;<br>в) алар нигезендә индивидуаль торак төзелеше яки бакча йорты төзелеше яки үзгәртеп кору башкарылган, төзелеш тәмамлануы турында хәбәрнамә, планлаштырыла торган төзелеш турында хәбәрнамә кергән көннән соң, ун ел үткәннән соң тапшырылган булса яки мондый индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йортын төзү планлаштырыла торган объект турында хәбәрнамә элек җибәрелмәгән булса (шул исәптән әлеге Кодексның 51.1 статьясындагы 6 өлеше нигезендә төзүчегә кире кайтарылган).<br>Әлеге пунктның 2 пунктчасында күрсәтелгән очракларда, төзелеш тәмамлану турындагы хәбәрнамә һәм аңа кушып бирелгән документлар мөрәҗәгать итүчегә кире кайтарыла, һәм хәбәрнамә җибәрелмәгән дип санала. | |
| 2.9. Дәүләт хезмәте | Дәүләт хезмәте бушлай күрсәтелә | РФ ШтК 55 ст. |

| | | |
|---|---|---|
| күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка төрле түләүнең тәртибе, күләме һәм алу нигезләре | | |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмалар тарафыннан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.11. Мондый түләү күләмен исәпләү методикасы турындагы мәгълүматны кертеп, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтүгә түләүне алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | РФ ШтК 55 ст. |
| 2.12. Дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәтен күрсәтү турында запрос биргәндә һәм | Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы запросны биргәндә һәм мондый хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта торуның максималь вакыты 15 минуттан да артмаска тиеш.<br>Дәүләт хезмәтләрен алучыларның аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән. | Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп |

| | | |
|---|---|---|
| мондый хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта торуның максималь вакыты | | юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы 601 нче номерлы указы |
| 2.13. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәте һәм хезмәтләр күрсәтү турында, шул исәптән электрон формада да, соратып алуны теркәү вакыты һәм тәртибе | Гариза кергән көнне.<br>Электрон рәвештә, ял (бәйрәм) көнендә кергән мөрәҗәгать, ял (бәйрәм) көненнән соң килгән эш көнендә теркәлә. | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урыннарга, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында запросларны тутыру урыннарына, аларны тутыру үрнәкләренә һәм һәр дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлегенә, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиа мәгълүматларын урнаштыру һәм рәсмиләштерү, шул исәптән федераль законнар һәм инвалидларны социаль яклау турында Татарстан | Дәүләт хезмәтен күрсәтү, янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган комитетның бинасында һәм бүлмәләрендә тормышка ашырыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен җайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла.<br>Инвалидларга, шул исәптән кресло-коляскадан һәм этләрдән файдалана торганнарга, бинадан һәм хезмәт күрсәтүләрдән файдалану мөмкинлеген тәэмин итү буенча чаралар гамәлгә ашырыла:<br>бинага һәм бүлмәләргә, шулай ук аларда күрсәтелә торган хезмәтләргә тоткарлыксыз керү шартлары;<br>Комитет территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү, Комитет бинасына керү һәм аннан чыгу, транспорт чарасына | «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы ; «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү |

| | | |
|---|---|---|
| Республикасы законнары нигезендә инвалидлар өчен күрсәтелгән объектларга керү мөмкинлеген тәэмин итүгә карата таләпләр | утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып;<br>күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт функциясе бозылуга ия булган инвалидларны озатып бару һәм аларга бинада һәм бүлмәләрдә ярдәм күрсәтү;<br>инвалидларның чикләүләрен исәпкә алып, биналарга, бүлмәләргә һәм хезмәт күрсәтүгә тоткарлыксыз үтеп керә алуын тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүматларны җайлы итеп урнаштыру;<br>инвалидлар өчен кирәкле тавыш һәм язма мәгълүматны, шулай ук язуларны, билгеләрне һәм башка текст һәм график мәгълүматны Брайльнең рельеф-ноктalы шрифты белән башкарылган билгеләр белән кабатлау, сурдотәрҗемәчене һәм тифлосурдотәрҗемәчене кертү;<br>Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Озатучы этнең махсус укытуын раслый торган документ формасын һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган форма һәм тәртиптә бирелә һәм махсус укытуны раслый торган документ булган очракта, бинага һәм бүлмәләргә, озатучы этне кертү;<br>хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга, башка затлар белән беррәттән, хезмәт алырга комачаулаучы киртәләрне үтәргә ярдәм итү.<br>Инвалидлар өчен дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның үтемлелеген тәэмин итү өлешендә таләпләр, 2016 елның 1 июленнән соң файдалануга тапшырылган, капиталь ремонт, үзгәртеп корылган, модернизация узган объектларга | һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары |

| | | |
|---|---|---|
| | карата кулланыла | |
| 2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану мөмкинлеге һәм сыйфаты күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәткәндә вазыйфаи затлар белән хезмәттәшлеге саны һәм аларның дәвамлылыгы, дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмати-коммуникацион технологияләр кулланып, дәүләт хезмәтен күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә (шул исәптән тулы күләмдә) дәүләт хезмәтен алу мөмкинлеге , башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль бүлекчәсендә мөрәҗәгать итүчене сайлау буенча (экстерриториаль принцип), Федераль законның 15.1 статьясында каралган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле | Дәүләт хезмәтеннән файдалана алу мөмкинлеге күрсәткечләре:<br>Комитет биналарының җәмәгать транспортына үтемлелек зонасында урнашуы;<br>кирәкле белгечләр саны, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итэлә торган бүлмәләр булу;<br>мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Комитетның рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтүнең ысуллары, тәртибе, сроклары турында тулы мәгълүмат булу; дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарның инвалидлар өчен уңайлы булуы;<br>инвалидларга башка затлар белән беррәттән хезмәт күрсәтүгә комачаулый торган киртәләрне җиңеп чыгуда ярдәм күрсәтү;<br>гаризаны электрон рәвештә бирү мөмкинлеге булу.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:<br>документларны кабул итү һәм карап тикшерү срокларын үтәү;<br>дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу срогын үтәү;<br>Комитет белгечләре тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү барышында бу регламентны бозу турында нигезле шикаятьләр булмау;<br>гариза бирүченең Комитет белгечләре белән аралашу саны:<br>-дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны шәхси тапшырганда - ике тапкырдан да артмау (консультацияләрне санамыйча) ;<br>-дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны почта аша яки электрон рәвештә тапшырганда – бердән дә артмау.<br>Дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза бирүченең Комитет | |

| | | |
|---|---|---|
| үзәкләрендә берничә дәүләт һәм (яки) муниципаль хезмәт күрсәтү турында соратып алу юлы белән (комплекслы запрос ) | (бүлек) белгече белән аралашу дәвамлылыгы 15 минуттан артмый.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү, шул исәптән, күпфункцияле үзәк, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкнең ераклашкан эш урыннары аша гаризаны тапшыру гамәлгә ашырылмый.<br>Экстерриториаль принцип буенча яки комплекслы соратып алу составында дәүләт хезмәте күрсәтелми.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Комитетка шәхси мөрәҗәгать иткәндә алынырга мөмкин | |
| 2.16. Башка таләпләр, шул исәптән экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен исәпкә алучы (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча бирелгән очракта) һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләре | Консультация телефон аша шәхси яки электрон хәбәр формасында электрон почта аша (e-mail: ojm@tatar.ru) Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең рәсми порталындагы Интернет-кабул итү бүлмәсе аша) http://ojm.tatarstan.ru) бирелергә мөмкин.<br>Гаризаны һәм документларны гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре аша, шул исәптән «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәре һәм Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша бирү мөмкинлеге бар. | 210-ФЗ номерлы Федераль закон |

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм башкару сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә үтәү үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә гамәлләрнең эзлеклелеген тасвирлау

3.1.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле хәбәрнамәне төзү һәм документларны рәсмиләштерү өлешендә;

2) төзелеш тәмамлану турында хәбәрнамәне һәм документларны кабул итү һәм теркәү;

3) кергән гаризаларны, документларны карау һәм туры килү (туры килмәү) турында хәбәрнамә әзерләү;

4) мөрәҗәгать итүчегә туры килү турында хәбәрнамәне бирү;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту;

6) техник хаталарны төзәтү.

3.2. Мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән хәбәрнамә төзү һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә.

Мөрәҗәгать итүче бүлеккә шәхсән, телефон һәм (яки) почта аша (шул исәптән электрон) дәүләт хезмәтен алу тәртибе турында консультация алу өчен мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә, шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле документлар формасы һәм башка мәсьәләләр буенча консультация бирә. Кирәк булганда, бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә, ярдәм күрсәтә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: консультация, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә.

3.3. Төзелешнең тәмамлануы турында хәбәрнамәне кабул итү һәм теркәү.

3.3.1. Мөрәҗәгать итүче шәхсән, ышанычлы зат, почта, электрон почта аша Комитетка дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза белән мөрәҗәгать итә.

Гариза Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша тапшырылырга мөмкин.

3.3.2. Әйдәп баручы киңәшче:

төзелеш тәмамлану турында хәбәрнамәне кабул итә һәм теркәп куя;

законлы вәкил булып килгән мөрәҗәгать итүченең яки дәүләт хезмәтен алучы затның вәкаләтләрен тикшерә;

әлеге регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларның булуын тикшерә;

гариза бирүчегә почта аша яисә электрон почта аша (аның теләге буенча) бирелгән документларның кирә торган номеры һәм кабул итү датасы турында тамга куеп, хәбәрнамәнең күчермәсен тапшыра.

3.3.1 һәм 3.3.2 пунктлары белән билгеләнә торган процедуралар Комитетта гариза һәм документларны теркәгән көндә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кабул ителгән һәм теркәлгән документлар.

3.4. Кергән гаризаларны, документларны карау һәм туры килү турында хәбәрнамә әзерләү.

3.4.1. Кергән гаризаларны, теркәлә торган документларны карау.

Бүлек белгече әлеге Регламентның 2.5 пункты таләпләренә туры килү-килмәүне тикшерә;

төзелеш тәмамлануы турындагы хәбәрнамәдә күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йорты параметрларының, планлаштырыла торган төзелеш турындагы хәбәрнамә кергән көнгә гамәлдә булган, рөхсәт ителгән капиталь төзелеш объектларын үзгәртеп кору, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре, территорияне планлаштыру документлары һәм РФ ШтК, башка федераль законнар белән билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрларына карата мәҗбүри таләпләргә карата билгеләнгән капиталь төзелеш объектларын төзү, үзгәртеп кору параметрларына туры килү-килмәүне тикшерә;

планлаштырыла торган төзелеш яисә бер типтагы архитектура хәбәрнамәсендә кушымта булып килгән, планлаштырыла торган төзелеш хәбәрнамәсендә күрсәтелгән, федераль яки региональ әһәмияттәге тарихи җирлек чикләрендә индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын төзү яки үзгәртеп кору очрагында, индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын карау юлы белән, индивидуаль торак төзелеше объектының яки бакча йортының тышкы кыяфәтенә мондый объектның яки йортның тышкы кыяфәте тасвирламасына туры килү-килмәүне тикшерә,

